| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2025 Олы Урсак ав. №2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кайбыч муниципаль районының Чукри-Алан торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2025 елның 22 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлегенең Чүкри Алан торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Җәлил урамы, Чүкри Алан авылы, 15а номерлы йорт янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Русак авыл җирлегенең Чүкри-Алан торак пункты территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 1000 (мең) сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын карап тоту).

«РИЗА» «КАРШЫ»?

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгьлүмат-телекоммуникация челтәрендә http://brusakov-kavbici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Урсак авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Нуреев